МЭР
ГОРОДА БАВЛЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

24.04.2019 Баулы шәһәре № 18

Җир участогының рөхсәт ителгән
төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча
Баулы шәһәрендә ачык тыңлаулар
билгеләү турында

Баулы шәһәрендә яшәүчеләрнең ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән җир участогын һәм капиталь төзелеш объектларын файдалануның рөхсәт ителгән төрен башка төргә үзгәртү мәсьәләсе буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 нче статьясы һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә

К А Р А Р И Т Т Е М:

1. Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Панарин урамы, 48 нче йорт адресы буенча урнашкан 16:55:010111:782 кадастр номерлы, 1033 кв. м мәйданлы җир участогының рөхсәт ителгән файдалану төрен «шәхси торак төзелеше өчен» дигәннән «дини максатта файдалану» дигәнгә үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. Билгеләргә:

- ачык тыңлаулар үткәрү датасын әлеге карар Интернет челтәрендә htpp//bavly.tatar.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында һәм htpp//pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүмат рәсми порталында басылып чыкканнан соң 20 көн узгач билгеләргә;

- үткәрү урынын:Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4 йорт, 21 нче кабинет адресы буенча «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитетында.

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итәлә ала торган адрес: Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4 нче йорт, 23 нче кабинет (эш көннәрендә - 9.00 дән 15.00 гә кадәр).

3. Ачык тыплауларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы итеп Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының баш белгече С. Ю. Чахееваны билгеләргә (алга таба - баш белгеч).

4.Баш белгеч тәэмин итәргә тиеш:

4.1.Ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү буенча закон таләпләрен, муниципаль хокукый актларны үтәүне;

4.2. Кызыксынган затларга ачык тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирүне.

5. Кушымта нигезендә, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм тикшерү буенча эшче төркем төзергә.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә htpp//bavly.tatar.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында һәм htpp//pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы шәһәре мэры Р.Х. Гатиятуллин

Баулы шәһәре мэрының
2019 елның 24.04
кабул ителгән 18 санлы
карарына кушымта

Кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү
һәм тикшерү буенча эш төркеме
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Бакиров Данияр Ленар улы | - | «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарама комитеты җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе; |
| Чахеева Светлана Юрьевна | - | «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты баш белгече; |
| Гыймаев Айнур Азат улы | - | Баулы муниципаль районының «Водоканал» муниципаль казна предприятиесе директоры; |
| Кыямов Алмаз Әхтәм улы | - | Дәүләттеркәү, кадастр һәм картография Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Баулы бүлеге начальнигы (килештерү буенча); |
| Никитин Виталий Владимирович | - | «Газпром теплоэнерго Казань» ЧҖҖ «Баулы» филиалы директоры (килештерү буенча); |
| Михайлова Алина Анатольевна | - | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе; |
| Хәсиятуллина Роза Ильяс кызы | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы |
| Хәбипов Равил Нуриман улы | - | «Бөгелмәгаз» ЭПУ Баулы районы газдан файдалану хезмәте начальнигы (килештерү буенча). |